КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 17 март г.Казань № 230

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасының дәүләт учреждениеләре җитәкчеләре вазыйфаларын биләүче затларның, аларның ирләренең (хатыннарының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турындагы, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре хакындагы мәгълүматларны Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары рәсми сайтларында урнаштыру һәм бу мәгълүматларны массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» 2014 ел, 19 март, 171 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт учреждениеләре җитәкчеләре вазыйфаларын биләүче затларның, аларның ирләренең (хатыннарының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турындагы, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре хакындагы мәгълүматларны Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары рәсми сайтларында урнаштыру һәм бу мәгълүматларны массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 ел, 19 март, 171 нче карарына үзгәрешләр кертү турында» 2023 ел, 2 ноябрь, 1400 нче.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин